**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

01.07.2019 677-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2017 елның 19 декабрендәге 1528-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга бәйле дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслар министрлыгының норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2017 елның 19 декабрендәге 1528-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыруга бәйле дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тикшерүләрнең бердәм реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – тикшерүләрнең бердәм реестры), «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертү билгеләнгән тәртиптә ТР ЭТРМның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт күзәтчелеге түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе;

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – РФ КоАП);

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК);

Россия Федерациясе Су кодексы (алга таба – РФ СК);

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе законы (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» РФ законы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 10, 823 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 89-ФЗ номерлы Федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1998, № 26, 3009 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Атмосфера һавасын саклау турында» 1999 елның 4 маендагы 96-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 96-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 18, 2222 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 7-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 2, 133 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы Федераль закон)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 52, 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 99-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 19, 2716 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 416-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 50, 7358 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 1, 26 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, рациаль файдалануга һәм саклауга дәүләт күзәтчелеге турында нигезләмә раслау турында» 2005 елның 12 маендагы 293 номерлы карары (алга таба – 293 номерлы РФ Хөкүмәте карары)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 20, 1885 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Объектларны су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелегенә тиешле һәм

су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелегенә тиешле объектларга кертү критерияләре турында» 2006 елның 4 ноябрендәге 640 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 45, 4713 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының көчен югалтуын тану турында» 2013 елның 5 июнендәге 476 номерлы карары (алга таба – 476 номерлы РФ Хөкүмәте карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 10 июнь, бастырып чыгару номеры: 0001201306100017, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җир асты байлыклары турында Россия Федерациясе законнары бозылу нәтиҗәсендә җир асты байлыкларына китерелгән зыян күләмен исәпләп чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 4 июлендәге 564 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 28, 3830 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «I-IV хәтәрлек классларына караган калдыкларны паспортлаштыру тәртибе турында» 2013 елның 16 августындагы 712 номерлы карары (алга таба – 712 номерлы РФ Хөкүмәте карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 34, 4443 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт экология күзәтчелеге турында» 2014 елның 8 маендагы 426 номерлы карары (алга таба – 2014 елның 08 маендагы 426 номерлы РФ Хөкүмәте карары)(Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы) (www.pravo.gov.ru), 2014, 13 май, бастырып чыгару номеры: 0001201405130016, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан контрольлек чараларын уздыруга җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү турында» 2014 елның 10 июлендәге 636 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2014, № 29, 4142 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «I-IV хәтәрлек классларына караган калдыкларны җыю, транспорт белән күчерү, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү турында» 2015 елның 3 октябрендәге 1062 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2015 елның 03 октябрендәге 1062 номерлы карары)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы), 2015, № 41, 5670 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан

алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата уздырыла торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 44, 6127 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы) (www.pravo.gov.ru), 2016, 20 апрель, бастырып чыгару номеры: 0001201604200019);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркыныч-юнәлешле якын килү алымын куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 806 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы) (www.pravo.gov.ru), 2016, 26 август, бастырып чыгару номеры: 0001201608260025, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуга юл куймау турында кисәтү төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә карата ризасызлыклар тапшыру һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары)(Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 14 февраль, бастырып чыгару номеры: 0001201702140002, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) эшләүгә һәм раслауга карата гомуми таләпләр раслау турында» 2017 елның 13 февралендәге 177 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, №9, 1359 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан файдаланыла торган, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган җитештерү объектларын төбәк дәүләт экология күзәтчелеге өчен билгеле бер куркынычлылык категориясенә кертү критерияләре турында һәм күрсәтелгән

күзәтчелекне гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» 2017 елның 22 ноябрендәге 1410 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 1410 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 27 ноябрь, бастырып чыгару номеры: 0001201711270023);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2018 елның 21 апрелендәге 482 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 18, 2633 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан зарури таләпләр, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләр бозылуны профилактикалау буенча чараларны оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата гомуми таләпләр раслау турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1680 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2018, № 53, 8709 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында әлеге документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2016, 22 апрель, бастырып чыгару номеры: 0001201604220035, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Су законнары бозылу нәтиҗәсендә су объектларына китерелгән зыян күләмен исәпләп чыгару методикасын раслау турында» 2009 елның 13 апрелендәге 87 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Табигать министрлыгының 87 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 24 июнь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Су объектлары милекчеләре һәм судан файдаланучылар тарафыннан су объектларыннан су ресурсларын алу күләмен һәм агынты суларны һәм (яисә) дренаж суларын ташлау күләмен, аларның сыйфатын исәпкә алып бару тәртибен раслау турында» 2009 елның 8 июлендәге 205 номерлы боерыгы (алга таба – Россия

Табигать министрлыгының 205 номерлы боерыгы)(«Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене», № 39, 2009, 28 сентябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Әйләнә-тирә мохитне саклау объекты буларак туфракларга китерелгән зыян күләмен исәпләп чыгару методикасын раслау турында» 2010 елның 8 июлендәге 238 номерлы боерыгы («Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене», №40, 2010, 4 октябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Калдыклар белән эш итү өлкәсендә исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2011 елның 1 сентябрендәге 721 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Табигать министрлыгының 721 номерлы боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2011, № 44, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынты дәрәҗәсенә карап калдыкларны I-V хәтәрлек классларына кертү критерияләрен раслау турында» 2014 елның 4 декабрендәге 536 номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 31 декабрь, бастырып чыгару номеры: 0001201512310003);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнар тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 21 март, бастырып чыгару номеры: 0001201703210041);

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» ТР законы)(Татарстан Республикасы Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2000, № 2, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, үзгәртеп рәсмиләштерү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибен раслау турында» 2009 елның 12 октябрендәге 715 номерлы карары (алга таба – ТР МК 2009 елның 03 октябрендәге 715 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм

боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы», 2009, № 40, 1677 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының һәм Биология ресурслары буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлекләрен раслау турында» 2011 елның 21 сентябрендәге 784 номерлы карары (алга таба – ТР МК 2011 елның 21 сентябрендәге 784 номерлы карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы», 2011, № 40, 2038 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 елның 04 ноябрендәге 917 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2011, № 47, 2507 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә үзләренә бүлеп бирелгән тау бүлемтекләре чикләрендә файдалы казылмаларны разведкалау һәм табу белән шөгыльләнүче яисә берләштерелгән лицензия буенча файдалы казылмаларны геологик өйрәнүне, разведкалауны һәм табуны җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан шәхси җитештерү һәм технологик ихтыяҗлар өчен гомумтаралган файдалы казылмаларны табу тәртибен раслау турында» 2011 елның 21 декабрендәге 1042 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 4, 0120 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир хуҗалары һәм җир кишәрлекләрен арендага алучылар тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмаларны табу, җир асты корылмалары төзү һәм көнкүреш коелары һәм скважиналар кору тәртибен раслау турында» 2012 елның 29 февралендәге 171 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 26, 0859 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында начар һава шартлары булган чорларда атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдә ташландыкларын җайга салу эшләрен оештыру турында» 2012 елның 22 маендагы 407 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма

хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 41, 1325 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләре үтәлүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 2012 елның 31 декабрендәге 1192 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, № 7, 0194 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 елның 21 августындагы 603 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2014, № 64, 1987 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында» 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы карары (алга таба – 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы ТР МК карары)(Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2018, № 77, 2491 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Су объектларыннан файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелегенә тиешле объектлар исемлеген раслау турында» 2012 елның 31 июлендәге 286-п номерлы боерыгы («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 91, 2987 ст.);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чараларын уздыруга биремнәр һәм аларның эчтәлеген рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән бәйләнешкә кермичә контрольлек чаралары нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибен раслау турында» 2017 елның 6 декабрендәге 1465-п номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2018, №18, 0696 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

1.5 пунктта:

«юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан үтәү» сүзләреннән соң «, шул исәптән 473-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары булып торган (алга таба – АСИҮС резидентлары),» сүзләрен өстәргә»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«АСИҮТ резиденты статусы бирелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата төбәк дәүләт күзәтчелеге гамәлгә ашырылганда 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясы нигезләмәләре исәпкә алына.»;

1.7 пунктта:

11 пунктчага «, 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында» сүзләрен өстәргә;

15 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

1.11 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә тикшерүләрләрнең бердәм реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат;»;

2 бүлектә:

2.10 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«АСИҮТ резидентларына карата планлы тикшерүне үткәрү вакыты аны үткәрү вакытыннан алып унбиш эш көненнән артмый. Кече эшкуарлык субъекты булып торучы бер АСИҮТ резидентына карата урынга чыгып планлы тикшерүләр уздыруның гомуми срогы бер елга кече предприятие өчен кырык сәгатьтән һәм микропредприятие өчен ун сәгатьтән артык була алмый. Тикшерүне уздыручы ТР ЭТРМ вазыйфаи затларының нигезле тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы махсус тикшеренүләрне һәм экспертизаларны уздыру зарурлыгына бәйле искәрмәле очракларда, тикшерү уздыру срогы озынайтыла, ләкин кече предприятиеләргә карата иң күбе ун эш көненә һәм микропредприятиеләргә карата иң күбе ун сәгатькә.

Бер АСИҮТ резидентына карата планнан тыш тикшерү уздыру срогы биш эш көненнән артык була алмый.»;

2.13 пунктның уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәрге чорда үзләре турында белешмәләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы нигезләмәләргә ярашлы нигездә кече эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр 294-ФЗ номерлы Федераль законның 26.2 статьясындагы таләпләргә ярашлы рәвештә оештырыла һәм үткәрелә.»;

2.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.17. Зарури таләпләр бозылуга юл куйган зат турында дөрес мәгълүмат, әлеге Регламентның 2.14 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүматлар булмаганда, ТР ЭТРМның вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан килгән мәгълүматка беренчел тикшерү үткәрелергә мөмкин. Килгән мәгълүматка беренчел тикшерү үткәрү барышында гаризаны һәм мөрәҗәгатьне җибәргән,

мәгълүматлар җиткергән затлардан өстәмә белешмәләр һәм материаллар (шул исәптән телдән тәртиптә) соратып алу буенча чаралар күрелә, юридик затның, шәхси эшкуарның ТР ЭТРМ карамагында булган документлары карап тикшерелә, зарурлык булганда, юридик зат, шәхси эшкуар белән бәйләнешкә кермичә генә һәм күрсәтелгән затларга мәгълүматлар тапшыру һәм ТР ЭТРМ таләпләрен үтәү буенча бурычлар йөкләмичә генә контрольлек буенча чаралар үткәрелә. Беренчел тикшерү кысаларында юридик заттан, шәхси эшмәкәрдән алынган мәгълүматка карата аңлатмалар соратылырга мөмкин, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка төрле документларны тапшыру мәҗбүри булып саналмый.»;

2.18 пунктта «зарури таләпләр бозылуы турында яки» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 бүлектәге 2 нче таблицаның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| 5. Су чыгаруның үзәкләштерелгән системасы аша агынты су ташлануга төбәк дәүләт экология күзәтчелеге | | | |
|---|---|---|---|
| 5.1. Агынты суларны агызу максатларында абонентлар тарафыннан су объектларыннан файдалану | 5.1.1. Үзәкләштерелгән су бүлү системалары аша су объектларына рөхсәт ителгән ташландык суларны агызу нормативларын үтәү | 7-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясындагы 4 пункты, 416-ФЗ номерлы Федераль законның $30^1$, $30^3$ статьялары | агынты суларның составы һәм үзлекләре турында декларация |

5 бүлектә:

5.1 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«АСИҮТ резидентларына карата дәүләт күзәтчелеге әлеге Регламент нигезендә һәм 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясында, РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карарында, Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

АСИҮТ резидентларына карата планлы тикшерүләр дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә уртак тикшерүләр рәвешендә уздырыла.»;

5.8 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) административ процедура нәтиҗәләре турында белешмәләр – билгеләнгән тәртиптә тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат.»;

5.17 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) административ процедура нәтиҗәләре турында белешмәләр – билгеләнгән тәртиптә тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат.»;

түбәндәге эчтәлекле $5.20^1$ пункт өстәргә:

«5.20[1]. Планлы тикшерү уздырганда ТР ЭТРМ вазыйфаи затлары тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) файдаланырга тиеш.

Тикшерү кәгазьләрен (контроль сораулар исемлекләрен) куллану барлык юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы тикшерү барышында гамәлгә ашырыла.

Планлы тикшерү уздырылганда кулланыла торган тикшерү кәгазьләрендә (контроль сораулар исемлекләрендә) юридик затка һәм шәхси эшкуарга белдерелә торган, гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә зыян салыну куркынычы барлыкка килүгә, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр куркынычына юл куймау күзлегеннән караганда үтәлеше аеруча әһәмиятле булган зарури таләпләргә кагылышлы сораулар була.

Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы тикшерү предметы тикшерү кәгазьләренә кертелгән сораулар исемлеге (контроль сораулар исемлекләре) белән чикләнә.

Тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча тутырылган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) тикшерү актына теркәлә.»;

5.46 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- административ процедура нәтиҗәләре турында белешмәләр – билгеләнгән тәртиптә тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат.»;

5.49 пунктка түбәндәге эчтәлекле кызыл юл өстәргә:

«Күрсәтмә 473-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясы таләпләрен үтәп, АСИҮТ резидентына тапшырыла (җибәрелә).»;

5.56 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) административ процедура нәтиҗәләре турында белешмәләр – билгеләнгән тәртиптә тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контрольлек (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт чишелеше» дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат.»;

5.58 пунктта:

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3) юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеге яки гамәлләре турында федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган бүтән Россия Федерациясе актлары нигезендә ТР ЭТРМ тапшырырга тиешле булган (шул исәптән федераль дәүләт мәгълүмат системалары ярдәмендә) яки ТР ЭТРМ тарафыннан (шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында) юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителә торган бүтән Россия Федерациясе актларында каралмаган йөкләмәләрне йөкләмичә алынырга мөмкин булган мәгълүматларга анализ ясау юлы белән зарури таләпләр үтәлешен күзәтү;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Планлы (рейд) тикшерүләр конкрет юридик затка, шәхси эшкуарга карата үткәрелә алмый һәм тикшерүне алмаштырырга тиеш түгел.»;

7 бүлектә:

7.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.4. Шикаятькә җавап яисә шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап түбәндәге очракларда бирелми:

1) әгәр язмача шикаятьтә шикаятьне юллаган мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (юридик затның атамасы, шәхси эшкуарның фамилиясе) яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми (әгәр күрсәтелгән шикаятьтә әзерләнә, кылына яки кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә туры китереп тиешле дәүләт органына җибәрелергә тиеш);

2) әгәр шикаятьтә цензурасыз яисә мыскыллы гыйбарәләр, ТР ЭТРМ вазыйфаи затының, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар булса, шикаять асылы буенча анда куелган сорауларга җавапсыз калдырылырга мөмкин (мондый шикаятькә ТР ЭТРМ вазыйфаи заты хокуктан явызларча файдалануның ярамавы турында шикаятьне җибәрүчегә хәбәр итәргә хокуклы);

3) әгәр язмача шикаятьнең тексты укылышлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләренә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укылышлы булса;

4) әгәр мөрәҗәгать итүченең язмача шикаятендә аның асылы буенча элек җибәрелгән шикаятьләренә бәйле рәвештә инде берничә мәртәбә язмача җаваплар бирелгән сорау бәян ителгән булса һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә министр, ТР ЭТРМ вазыйфаи заты, күрсәтелгән шикаятьнең һәм элек җибәрелгән шикаятьләрнең бер үк күзәтчелек органына яисә бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән булуы шарты белән, чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм шушы мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Бу карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

5) шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә;

Ә) әгәр язмача мөрәҗәгать тексты шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка алар компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән затка хәбәр ителә;

7) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта җавабы урнаштырылган сорауны үз эченә алган язмача шикаять килгән очракта, шикаятьне җибәргән затка шикаятьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә, шикаятьтә куелучы сорауга «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җавап урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресы турында хәбәр ителә, бу вакытта суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять кире кайтарылмый;

8) суд карарына шикаять белдерелгән шикаять теркәлгән көненнән башлап җиде көн дәвамында, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире җибәрелә.»;

8 нче кушымтада:

«соратып алына торган документның исеме һәм (яки) соратып алына торган мәгълүмат» графасында «лицензия» сүзен «лицензиядән мәгълүматлар» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэминат бүлегенә (А.Е.Никулин) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрының беренче урынбасары Ф.Ф. Шакировка йөкләргә.

Министр в.в.б. Ф.Ф.Шакиров